**Татар теле дәресе**

**Тема:** Хайваннар. 2 нче сыйныф (рус төркеме)

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

**Шәхескә кагылышлы:** эшчәнлекнең максаты һәм нәтиҗәсе арасындагы бәйләнешне билгеләү; телнең байлыгын, үзенчәлекләрен аңларга омтылу; хайваннарга карата хөрмәт тәрбияләү.

**Метапредмет:**

**Танып-белү УУГ:** сөйләмне кабул итү һәм аның эчтәлегендә ориентлашу, төп төшенчәләрне аеру, аңлап һәм ирекле сөйли белү.

**Коммуникатив УУГ:** укытучының, сыйныфташларның сөйләмен, чит кеше сөйләмен аңлау, тыңлый белү, коммуникатив максатлардан чыгып, сүзләрне, җөмләләрне дөрес һәм урынлы куллану, фикерне төгәл һәм ачык итеп җиткерә белү.

**Регулятив УУГ:** дәреснең темасын һәм максатын формалаштыру, эшчәнлек төрләрен сайлау, хаталарны төзәтү, анализлый, бәяли алу.

**Предмет буенча:** “Хайваннар” темасы буенча өйрәнелгән лексик берәмлекләрне дөрес куллана белү, тема буенча диалог һәм монолог төзи белү.

**Дәреснең тибы:** белемнәрне системалаштыру дәресе.

**Төп төшенчәләр:** хайваннар белән бәйләнешле сүзләр.

**Предметара бәйләнеш**: әйләнә-тирә, табигать белеме

**Эшне оештыру:** фронталь, төркемдә, парларда, индивидуаль.

**Җиһазлау:** проектор, ноутбук, презентация, видео һәм аудио материал, “серле” тартма, биремле карточкалар.

**Дәреслек:** Бәхтиев Р.Ф., Гаппасова Р.Ч., Карпухина Н.И., Кашафетдинова Г.В., Маркова Э.М., Хөснетдинова Х.Х., Якупов Р.Н. Сәлам! 2нче сыйныф: рус телендә белем бирү оешмаларының татар телен өйрәнүче укучылары өчен уку әсбабы. – Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшрияты, 2018.

| **Дәрес этабы** | **Укытучы эшчәнлеге** | **Укучы эшчәнлеге** | **Универсаль уку гамәлләре (УУГ)** |
|---|---|---|---|
| **Оештыру, мотивлаштыру** | Уңай психологик халәт яки эш атмосферасы тудыра.<br><br>1)Исәнләшү.<br>-Исәнмесез,укучылар!<br>- Исәнмесез!<br>- Хәлләр ничек? (җавап бирәләр)<br>2) Уңай психологик халәт тудыру.<br>3) Бер-берегезгә елмаегыз. Хәерле көн теләгез. | Сыйныф эшкә әзерләнә (укытучыны тыңлыйлар, сәламлиләр, җырлыйлар,сораулар га җавап бирәләр, | **ТБУУГ:** тыңлап аңлау һәм нәтиҗә чыгару.<br>**КУУГ:** укытучы һәм сыйныфташлар белән хезмәттәшлек итү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | "Сәлам!" җырын җырлау.<br>Сәлам, сәлам! Хәерле иртә!<br>Сәлам, сәлам! Хәерле иртә!<br>Хәлләр ничек? Бик шәп, рәхмәт!<br>Сау бул, дустым! Хәерле көн!<br>Сәлам, сәлам! Хәерле көн!<br>Сәлам, сәлам! Хәерле көн!<br><br>Хәлләр ничек? Бик шәп, рәхмәт!<br><br>Сау бул, дустым! Хәерле кич!<br>Рәхмәт,укучылар! Кызлар утыралар, малайлар да утыралар.<br><br>-Без бүген 2 төркемгә бүленеп эшләрбез.<br><br>–Төркемнәрдә эшләү кагыйдәләрен искә төшереп китик. | сөйләм эшчәнлегенә кушылалар).<br><br>Искә төшерәләр. | **РУУГ:** эш урынын оештыру.<br><br>**Шәхескә кагылышлы:** укытучы һәм сыйныфташларга хөрмәт, дәрескә әзерлеккә үзбәя бирү. |
| **Танып-белүне оештыру** | Дәреснең темасын, максатын формалаштырырга тәкъдим итә.<br><br>–Балалар, карагыз әле, миндә "серле" тартма бар. Ачып карыйбызмы? Нәрсә бар икән? | Ачалар, карыйлар (конверт, конверт | **РУУГ:** уку мәсьәләсен дөрес аңлауны бәяләү, планлаштыру |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | –Табышмакны укыгыз, җавабын табыгыз.<br><br>–Димәк, без бүген нәрсә турында сөйләшербез? | эчендә язу, табышмак) Табышмакны укыйлар, җавабын табалар .<br><br>–Хайваннар турында. | **КУУГ**: үз фикереңне төгәл әйтә белү |
| **Лексик күнекмәләрне камилләштерү** | **Кайтаваз уены. С**үзләрнең әйтелеше өстендә эш. (төлке, куян, керпе, кәҗә, сарык, бүре, аю, эт, песи ) Кул колакка куелса, балалар кабатлыйлар.<br><br>-Балалар, хайваннар нинди ике төркемгә бүленә? (йорт хайваннары, кыргый хайваннар)<br><br>-Йорт хайваннары кайда яши?(авылда,өйдә,фермада) Кыргый хайваннар?(урманда, зоопаркта)<br><br>**“Серле тартма”** уены.Хайваннарны алалар, исемен, кайда яшәгәнен әйтәләр.<br><br>**Пантомима** уены. Командадан чыгып | Тыңлыйлар, әйтәләр, төзәтәләр.<br><br>Җавап бирәләр | **ТБУУГ**: сөйләм эчтәлегендә ориентлаша белү<br><br>**КУУГ**: үз фикереңне төгәл әйтә белү<br><br>**РУУГ**: хаталарны табу ,төзәтү, төркемнәрдә эшли белү |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | күрсәтәләр, икенче команда белергә тиеш. | | |
| **Диалогик сөйләм күнекмәләрен камилләштерү** | **“Бу нәрсә?” уены.**<br><br>**Ул ак, куркак, урманда яши, кишер ярата.**<br><br>**Ул зур, авылда яши, үлән ярата.**<br><br>**Ул хәйләкәр, матур, урманда яши.**<br><br>**Кечкенә, матур, өйдә яши, сөт ярата**<br><br>**Зур, көрән, урманда яши, бал ярата**<br><br>**Ул фермада яши, йон, ит бирә.**<br><br>**Нәрсә ярата? уены.** Һәр төркем хайваннарның нәрсә яратканын әйтә.<br><br>–Ә хәзер сез парларда эшләп алыгыз әле | Текстларны тыңлыйлар,нәрсә икәнен әйтәләр<br><br>Тыңлыйлар,сораулар га җавап бирәләр.<br><br>Парларда эшлиләр. | **КУУГ:** укытучы һәм сыйныфташлары белән хезмәттәшлек итә белү, үз фикереңне дәлилли белү<br><br>**РУУГ:** парларда эшли белү |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | (ситуатив күнегүләр бирелә)<br><br>Узнай у друга:<br><br>–есть ли у него кошка, какая она;<br><br>–коза что любит?Ачто нам дает коза?<br><br>–есть ли у него собака, как ее зовут, что делает?<br><br>-лиса какая, где живет?<br><br>- заяц какой и что любит?<br><br>-в зоопарке есть медведь? что любит? | | |
| **Ял минуты. (Без урманга барабыз,**<br><br>**җиләк, гөмбә җыябыз.**<br><br>**Карыйбыз: аю, бүре юкмы икән,** | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Әгәр булса чабабыз)** | | | |
| **Монологик сөйләмне камилләштерү** | –Балалар, һәр командага маска бирәм.Сез шул хайван турында сөйләргә тиешсез.<br>–Балалар, мультфильм карарга яратасызмы? Бу мультфильм тавышсыз. Сезгә шундый бирем бирделәр: мультфильмга хикәя уйларга, сөйләргә (озвучить). Үзегезне актерлар итеп хис итегез әле, сөйләгез (озвучьте). | Төркемдә эшлиләр, сөйлиләр<br>Төркемнәрдә эшлиләр. Һәр төркем үз вариантын сөйләп күрсәтә. | **ТБУУГ**: рәсем буенча эшли белү, төп төшенчәләрне аеру.<br>**КУУГ:** аңлап һәм иркле сөйли белү, төркемнәрдә эшли белү.<br>**РУУГ:** эшчәнлекне оештыра белү, җавапларны бәяли белү. |
| **Рефлексия** | Дәрес, дәрестә туган авырлыклар турында сорый, дәрескә нәтиҗә ясый, укучыларның эшенә бәя бирә. Өй эшен аңлата. | Үзбәя. Сораулар бирәләр, өй эшен сайлыйлар, язып алалар. | **ТБУУГ:** биремнәрне аңлау<br>**РУУГ:** индивидуаль |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | –Балалар,без бүген нәрсә турында сөйләштек?<br><br>–Хайваннар нинди була?<br><br>-Кайда яши?<br><br>-Нәрсә бирә?<br><br>-Аларны нишләргә кирәк?<br><br>–Үзегезне бәяләгез. (яшел, сары, кызыл төстәге смайликлар күтәрелә) Бер-берегезне мактагыз.<br><br>Өй эше:<br><br>1.Хайваннар турында табышмаклар табарга.<br><br>2.Яраткан хайван турында сөйләргә<br><br>3.Яраткан хайван рәсемен ясарга. | -Хайваннар<br><br>-Йорт хайваннары, кыргый хайваннар<br><br>-Авылда, урманда<br><br>-Сөт, ит, йон, мех, тире<br><br>-Яратырга,ашатырга сакларга | һәм коллектив эшне дөрес бәяли белү<br><br>**ШУУГ:** эшчәнлекнең максаты һәм нәтиҗәсе арасындагы бәйләнешне билгели белү,үз уңышларың яки уңышсызлыкларың<br><br>ның сәбәбен ачыклау<br><br>**КУУГ:** әңгәмәдә катнашу, фикерләрне дәлилле итеп җиткерү |